Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

№33 (46)

22 ноябрь 2012 ел

12+

## • Универ хәлләре

16 **НОЯБРЬ КӨННЕ УНИВЕРСИТЕТЫБЫЗ** УНИКСның зур концертлар залында үзенең 208 **ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ**. Әзерләнгән бәйрәм концерты бик югары дәрәҗәдә оештырылган иде. Барлык студентлар, укытучылар һәм килгән кунаклар бик кәнагать калып, уңай тәэсирләр белән кайтып китте. Яр Чаллы филиалы да актлар залында бу уңайдан тамашачылар кабул итеп, тантаналы концерт уздырган.

• • • •

**19 НОЯБРЬ КӨННЕ РЕКТОРАТ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Киңәшмәне КФУ ректоры Илшат Гафуров яхшы яңалыктан башлап җибәрде. Университетыбызның бер төркем галимнәренә мәгариф өлкәсендә хезмәтләре өчен Россия Хөкүмәте премиясе тапшырылды. Социаль фәннәр докторы, уку-укыту эшләре буенча КФУ проректоры Рияз Минзарипов; психология фәне докторлары, кафедра җитәкчеләре Леонид Попов, Александр Прохоров; фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Михаил Щелкунов «Югары һөнәри белем бирүнең иҗтимагыйпсихологик тәэмин итү методологиясе һәм мәгълүмати технологияләре» дип аталган хезмәтләр циклы өчен бу премиягә лаек булды. Җыелышта контроль йөкләмәләрнең үтәлеше турында хәбәр ителде. Финанс эшләре буенча проректор Рәйсә Муллакаева федераль максатчан программаларга бүленеп бирелгән акчаларның ни дәрәҗәдә үзләштерелүе турында мәгълүмат бирде. Телләр институты директоры Татьяна Иванова гуманитар-педагогик профильгә караган чит телләр кафедрасын һәм инглиз теле кафедрасын үзгәртеп коруның әһәмиятен аңлатты.

• • • •

**19 НОЯБРЬДӘ** Казан университетында «Россия» каналының директор урынбасары **СЕРГЕЙ БРИЛЕВ АЧЫК ЛЕКЦИЯ ҮТКӘРДЕ**. Үзе белән таныштырганнан соң, Россиядә булган һәм әле дә бара торган мөһим иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга мөнәсәбәтен белдерде. Катнашучыларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

• • • •

**19 НОЯБРЬДӘ** Яр Чаллы филиалы юридик факультетының 4 курс студенты **ЛӘЙСӘН НУРМӨХӘМӘТОВАГА** тантаналы рәвештә **РЕКТОР СТИПЕНДИЯСЕ ТАПШЫРЫЛДЫ**. Мондый төр стипендиягә ия булу өчен, фәнни-тикшеренү эшләрендә югары нәтиҗәләргә, укуда да яхшы күрсәткечләргә ирешергә кирәк.

• • • •

**ШУЛ УК КӨННЕ** КФУның Тарих музеенда беренче мәртәбә студентларның **МУЗЕЙ ПРОЕКТЛАРЫ ФЕСТИВАЛЕ БУЛДЫ**. Бу чараны оештыру идеясе быелның мартында ук туган. Студентлар үзләре дә проектлар төзеп караганнар. Анда «Татар авылы», Казан трамвае тарихы, «Эпоха», сәгатьләр музее һәм Туфан Миңнуллин өймузее кебек эшләрен тәкъдим иттеләр. Алар экспозицияләрне ничек эзләүләре, табулары, бизәлеш үзенчәлекләре турында тәҗрибә уртаклашты.

• • • •

**19 НОЯБРЬДӘ** КФУда физика, химия һәм биология фәннәренең уртак дисциплинара тикшеренүләренә багышланган **II КФУ-РИКЕН ХАЛЫКАРА СИМПОЗИУМЫ АЧЫЛДЫ**. Чарага РИКЕН галимнәре; физика, биология һәм химия фәнни лаборатория җитәкчеләре җыелды.

• • • •

**19 НОЯБРЬ КӨННЕ** Казан федераль университетында АКШтагы Җиденче суд округының Федераль судлар администрациясе җитәкчесе **КОЛЛИНЗ Т.ФИЦПАТРИК** (Чикаго, АКШ) кунакка **КИЛДЕ**. Ул Тарих музее, сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге белән танышып чыкты. Фицпатрик әфәнденең Россиягә визиты «Ачык дөнья» закон чыгару тармагы өлкәсендә АКШ тәҗрибә алышу программасы белән бәйле.

• • • •

**20 НОЯБРЬДӘ** университетның төп бинасында КФУның Чит ил студентлары һәм аспирантлары советы инициативасы һәм Тышкы элемтәләр департаменты булышлыгы ярдәмендә Якын һәм Ерак Көнчыгыш илләренә багышланган **ФОТОКҮРГӘЗМӘ АЧЫЛДЫ**. Чара «Халыклар дуслыгы» фестивале кысаларында уздырыла.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*









Алия Галимуллина фотолары

# Кореялы кунаклар

**Дания ФАТЫЙХОВА,**
хәбәрче

21 ноябрь көнне Татарстан Республикасына визиты кысаларында Казан федераль университетына Корея Халык Демократик Республикасының Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле вәкиле Ким Ен Дже килде.

Делегация составында КХДРның Түбән Новгородтагы Мактаулы консулы, «Нижегородрапс» ҖЧҖның генераль директоры Олег Ким, Татарстан Республикасы Президенты тышкы элемтәләр департаменты директор җитәкчесе, Америка, Европа һәм БДБ илләре бүлеге җитәкчесе Илдар Насыйров бар иде. Корея Халык Демократик Республикасы белән Советлар Союзы дәвереннән бирле дуслык мөнәсәбәтләребез ныклы. Россиядә коммунистик идеология булмаса да, илебез галимнәре КХДРдагы коллегалары белән тыгыз бәйләнештә тора, тәҗрибә уртаклаша. Бу очрашу да әлеге дуслык мөнәсәбәтләренең ачык бер күренеше.

Кунаклар Казан университеты үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән якыннан танышу өчен, Тарих музеенда булды. КФУ Президенты Мәкъзүм Сәлахов белән очрашу барышында, мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек итү турында фикер алыштылар. Ким Ен Дже мавыктыргыч очрашу һәм кызыклы экскурсия өчен, рәхмәт сүзләре җиткерде: «Кыска гына вакыт эчендә уку йорты турында шундый тулы мәгълүмат алдык. Россиянең тарихы һәм фәнгә зур өлеш керткәне өчен, Казан федераль университетына тирән хөрмәт хисләре белдерәбез», - дип язып калдырды ул университетның хөрмәтле кунаклар китабына.

## • Бездә кунак бар

# Җир хокукын өйрәндек

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Бүген Россиядә җир хокукына бәйле бәхәсләр еш туа. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының экология һәм җир хокукы кафедрасы профессоры, юридик фәннәр докторы Геннадий Волков 21-22 ноябрь көннәрендә университетыбызда җир хокукы мәсьәләләренә багышланган ачык лекцияләр үткәрде. Әлеге очрашуларда профессор бу өлкәдә иң кискен мәсьәләләрне чишү юлларын тәкъдим итте.

**Ахыры 3нче биттә.**



*Генадий Волков.* Алия Галимуллина фотосы

• Безнең канат

# Омскида Казан галимнәре

**Розалия САЙГАНОВА,**
Омск татары

ШУШЫ КӨННӘРДӘ ОМСК ШӘҺӘРЕНӘ ЭШЛЕКЛЕ СӘФӘР БЕЛӘН ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ КИЛДЕ. КАЗАН КУНАКЛАРЫНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ: ВАСИЛИЙ (ВИЛЬГЕЛЬМ ФРИДРИХ) РАДЛОВНЫҢ 140 ЕЛДАН СОҢ, 2012 ЕЛДА ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНДА КАБАТ БАСЫЛЫП ЧЫККАН «КӨНЪЯК СЕБЕРДӘ ҺӘМ ЖУНГАР ДАЛАЛАРЫНДА ЯШӘҮЧЕ ТӨРКИ КАВЕМНӘРНЕҢ СӨЙЛӘМЕ» ДИГӘН КИТАБЫН ТӘКЪДИМ ИТҮ ИДЕ.





Омскига КФУ профессоры Фәрит Йосыпов, КФУның Филология һәм сәнгать институты татар филологиясе бүлеге мөдире, профессор Флера Сәйфулина, шул ук университетның татар әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров килде.

Казан галимнәре кыска гына ике көн эчендә Себер татарлары тематикасы буенча эшләүче кайбер Омск галимнәре белән очрашырга, өлкәнең Тара һәм Омск шәһәрләрендәге татар җәмәгатьчелеге белән очрашырга, аралашырга өлгерде. Алар һәркайда көтеп алынган кадерле кунаклар булды.

Очрашуда катнашкан Омскиның «Татар дөньясы» газетасы мөхәррире Гөлсинә Әхмәрова: «Археология һәм этнография институты кафедрасында Себер татарлары буенча эшләүче галимнәргә Казан галимнәренең Радлов китабын тәкъдим итәргә килүләре хакында әйткәч, алар шунда ук, китапны алып киләләрме, дип зур кызыксыну белдерделәр. Китапны кулларына алгач, игътибар белән берничә минут беркем белән дә сөйләшмичә, фәкать китап белән генә таныштылар», – диде.

Шул ук көнне кунаклар өлкә үзәгеннән өч йөз чакрым ераклыкта урнашкан Тара шәһәренә юл тотты. Казан кунаклары кайчандыр Радлов йөргән юллардан үтте. Галимә Флера Сәйфулина Тарадагы очрашу турында бик дулкынланып сөйләде: «Ерак булуына карамастан, шул ук көнне Тара шәһәренә – атаклы сәүдәгәрләре, китапханәсе, татар җанлы, татар рухлы кешеләре, татар мәктәбе булган милли үзәккә бару мөмкинлеге тугач, бик сөендек. Татарлар монда безне туганнары кебек каршы алды. Чыннан да якташларым – 3-4 буын бабалары Буа, Апас якларыннан күченеп утырган гаиләләр белән дә таныштым. Радловның туган иленнән баш тартып, себер татарларын, төрки халыкларны өйрәнергә килгән галим булуы турында ишеткәч, гади халыкта аңа карата җылы хисләр туды. Китап турында да кызыксынып тыңладылар. Бер яктан, фәнни китап бит, ә халык үзенең киләчәге турында уйлый, тарихы белән кызыксына. «Нишләп бик аз санда алып килдегез? Өйләребездә Коръән бар, аның янында торырга тиешле китап бит бу!» – диде очрашуга килгән милләттәшләребез».

Радлов китабының кабат басылып чыгуына Фәрит Йосыповка керткән өлеше өчен, чиксез рәхмәтләребезне җиткерәбез. Галим китапның төзүчесе һәм аны яңадан бастырырга кирәклеген Татарстан хөкүмәтенә җиткерүче буларак та бик зур эш башкарган. Мин аны Радловның үзе белән чагыштырам. Ул 1957 елдан бирле ничә тапкыр Себер ягына килгән, халыкны өйрәнгән, мәдәниятен, тел байлыгын саклауга өлеш керткән. Барлык эшләгән эше дә халык өчен!

Казан галиме Илһам Гомәров: «Себер үзенең тарихы, кешеләре белән тартып китерә. Без Төмән, Тубыл якларында күп йөрдек. Экспедиция составында Фәрит абый белән дә килгәнем булды. Омскига беренче тапкыр килүем. Мондагы халыкка, очрашуларга бик хәйран калдык. Элек-электән килгән бәйләнешләребез сакланып калган, бүгенге көндә дә мондый аралашулар зарур дигән уй белән китәбез», – дип белдерде.

Казан кунакларына Омскидагы «Умырзая» татар-башкорт фольклор халык ансамбле һәм «Өмет» балалар үрнәк фольклор студиясе зур концерт тәкъдим итте. Омск-Казан арасы һәрчак шулай якын булсын!

• Галимнәребез

# Университетның энциклопедик галиме

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

ГАБДЕЛКАЮМ ГАБДЕННАСЫЙР УЛЫ НАСЫЙРОВ (1825-1902) – КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ, ЯЗУЧЫ ҺӘМ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТАНЫЛГАН МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ ТУРЫНДА БЕЛМӘГӘН КЕШЕ ЮКТЫР. Ә МЕНӘ АНЫҢ КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЕ КҮПЛӘРГӘ ЯҢАЛЫК БУЛЫРГА МӨМКИН.



Яшь чагыннан ук Каюм Насыйри белемгә тартыла: Казан мәдрәсәсендә укый, гарәп-фарсы телләрен өйрәнә, шулар белән беррәттән татар теле һәм рус теле буенча да белемнәрен арттыра. 1855 елдан аны Казан Духовное училищесына татар телен укытырга чакыралар. Бераз вакыт үткәч, Каюм Насыйри шул ук һөнәре белән Духовная семинариядә эшен дәвам итә. Биредә ул укытучылар белән таныша, башка фәннәр белән дә ныклап кызыксына башлый.

Каюм Насыйри Казан университетына ирекле тыңлаучы булып йөри башлый һәм шунда ук югары белем ала. Галимнең монда укуының әһәмияте турында Петербург университеты профессоры В.Григорьев: «Казан университетында алган гыйлеме Каюм Насыйрины исламга объектив карарлык югары дәрәҗәгә менгерде. Ул – бу яктан безнең Россия мөселманнары арасында беренче кеше», – дип бәяләп уза.

1885 елда Каюм Насыйрины Казан университетының Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең вәкиле итеп сайлыйлар. Ул – энциклопедик галим, чөнки аның биредә куйган күпкырлы эшчәнлеге төрле фән тармакларына карый: татар әдәбияты («Кырык вәзир кыйссасы», «Буш вакыт», «Кырык бакча», «Әбүгалисина», «Фәвакиһел җөласа фил-әдәбият»); татар теле («Дөрес һәм матур язу кагыйдәләре», «Әл-мүзәҗ», икетомлык татар теленең аңлатмалы сүзлеге, татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр), этнография, фольклор, педагогика һәм методика («Әхлак рисаләсе», «Утыз вәгазь», «Китап әт-тәрбия»); астрономия, математика («Хисаплык», «Гыйльме һәмдәсә»); география («Истилаһәте җәгърәфия»); физиология, ботаника һ.б.

Каюм Насыйри татар балаларына рус теле, дөньяви фәннәрне укытуга зур игътибар биргән, татар фәнен рус һәм чит ил фәннәре белән бер рәткә куярга омтылган. Һичшиксез, бу галим – татар мәдәниятенең үсешенә, татарларда белем дәрәҗәсен күтәреп, милләтебезне алга чыгаруда зур урын тоткан кеше. Аңа әлеге эшендә Казан университетында алган белемнәре һичшиксез ярдәм иткән.

• Белем баскычлары



# Белеме булган - меңне егар!

**Алинә САДЫЙКОВА, Рифат СӘЛАХ**

21 НОЯБРЬ БӨТЕНДӨНЬЯ ТЕЛЕВИДЕНИЕ КӨНЕ БУЛУ УҢАЕННАН, УНИВЕРСИТЕТ БЕЛӘН «ТАТМЕДИА» РЕСПУБЛИКА МАТБУГАТ ҺӘМ МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯЛӘР АГЕНТЛЫГЫ «РОССИЯ» ТЕЛЕКАНАЛЫНЫҢ I КАТЕГОРИЯЛЕ ОПЕРАТОР КОНСТАНТИН МУЧНИК БЕЛӘН ОЧРАШУ ОЕШТЫРДЫ.

Чара операторларга, яшь белгечләргә киңәш бирү, үзләренең һөнәрләре буенча дөнья күләмендә яңа тенденцияләр белән танышуны да исәптә тотып уздырылды.

Константин Мучник үзенең тәҗрибәсе белән уртаклашты. Бу өлкәдәэшләмәгәнкешегәаңлавыкыенрак булса да, очрашуга килгәннәр бик мавыгып тыңлап утырдылар, үзләрен кызыксындырган сорауларны яудырдылар. Сөйләшүнең төп темасы булып видеокамералар; аларның көн саен үзгәрүе, үзгәргән саен мөмкинлекләре дә артуы булды. Мәсәлән, бүгенге көндә иң популяр камера булып Sony исәпләнә (42% оператор шушы маркалы төшерү аппаратына гына ышана икән). Икенче урында Panasonic, ә Canon фирмасы продукциясе өченче урында гына. Камераларны бер урыннан икенче урынга күчерү бик зур көч таләп иткәнлектән, җитештерүчеләр аларны кечерәк, җиңелрәк итеп ясарга омтылалар. Бу исә, сурәтнең начараюына гына алып килә. Шуңа күрә яхшы сыйфатлы сюжет ясыйсыгыз килсә, тулырак ракурс белән, яктылык диодларыннан (алар 2 типта була һәм шәүләләрне тигезлиләр) файдаланып төшерергә кирәк. «Тагын бер мөһим әйбер: оператор белән корреспондент арасында үзара аңлашу, яхшы мөнәсәбәт булырга тиеш. Шулай булганда гына, югары дәрәҗәдә материал әзерләп була», – дип басым ясады Константин Мучник.

КФУ әлеге чараны оештырырга үзенең телестудиясен тәкъдим итте. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының матбугат үзәге җитәкчесе **Венера АБЯЗОВА** да:

Телевидениегез хезмәткәрләре дә ачык йөз белән каршы ала, телестудиягез дә менә дигән! Җиһазларыгыз да өр-яңа модель. Семинарлар күбрәк телевидение өлкәсенә караса да, үзәк телеканалларда эшләүче хезмәткәрләр биргән киңәшләрне көндәлек тормышта да кулланырга мөмкин. Үзем дә аларның сүзләренә колак салырга тырышам», – диде.



Мондый чаралар газета-журнал хезмәткәрләре өчен дә үткәреләме дип кызыксынгач, очрашуга танылган газета журналистларын да чакырырга вәгъдә бирде Венера ханым. Россия телеканалының директоры урынбасары Сергей Брилев, стилист Мария Бизяева кебек шәхесләрне университетыбызга кунакка «Татмедиа» агентлыгы һәм КФУ белән уртак проекты алып килде.

Россиякүләм билгеле журналистлар университетыбызга еш кунакка килә. Бу гаҗәп тә түгел. Университетыбыз ил күләмендә дә иң бай тарихлы һәм югары дәрәҗәле югары уку йортларының берсе бит.

● Юбилей


Автор фотосы

# Шигырь тулы гомер!

**Регина РАЯНОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Кеше гомере агымсуга тиң икән шул. Күз ачып йомганчы ел арты еллар үтә дә китә. Тормыш авырлыклары маңгайларга эз калдырып, тирән буразналар сыза. Чигәләргә чал йөгертә, ләкин йөрәк һәрвакыт унсигез яшьтәге кебек, яшь килеш кала бирә.

Сүзем шундый япь-яшь күңелле кешеләрнең берсе - шагыйрә, прозаик, публицист, галимә һәм укытучы Рифә Рахман турында. Моңсу күзләргә ямь өстәргә теләгәндәй, табигатьнең шушы мизгелендә ярты гасыр элек дөньяга килә. Барлык туганнарын сөендереп, үзенең тирә-ягындагы кешеләргә шатлык өләшеп, олысына да, кечесенә дә кешелекле һәм игелекле, абруйлы киңәшче булып яши Рифә Фәтхерахман кызы Харрасова. Аның иҗат кичәсе дә бик җылы үтте.

Бәйрәмгә шагыйрәнең иҗатташлары. Язучылар берлеге әгъзалары, Казан федераль университетының укытучылар коллективы, артистлар, укучылары һәм иң мөһиме: Рифә Рахманның әнисе, туганнары килде.

Рифә апа дәрес вакытында безгә еш кына гомере буе укытучы булып эшләгән әнисе турында сөйли. Ирешкән уңышларында яхшы тәрбия биргән әнисенең өлеше зур булуын әйтә ул. Бу бәйрәмнән соң, Рифә Рахманның әнисенә карата икеләтә хөрмәт һәм соклану хисе уянды. Өлкән яшьтә булуына карамастан, йөрәккә үтеп керерлек итеп котлады. Аның сүзләрендә йөрәк парәсына карата ярату да, кызының иҗатына бәя дә, горурлык хисләре дә чагыла иде.

Шулай ук аның туган төбәгеннән килгән кунаклар – Кукмаралы шагыйрә шигыренә көй язып, аны Казан тамашачыларына да җиткерде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, язучы Вакыйф Нуриев Рифә апаның иҗатына үзе алып килгән чәчәкләр кебек төрле һәм матур дип бәя бирде. Тукай музее директоры, шагыйрь Рәмис Аймәт үз сүзләренә язылган «Син минем җанымның яртысы» җырын Рифә апага багышлап җырлады.

Гадәттә, кеше гомер агышын туган көннәр белән исәпли, ә укытучы күзләр саен студентлар каршы алып, язын аларны зур тормыш юлына озатып, шушы еллар дәвамында алар белән бер тормыш кичерә. Шулай ук, Рифә Рахман да безнең өчен беренче чиратта тәҗрибәле остаз. Шуның өчен студентларга сүз бирелгәч, алар бик үзенчәлекле итеп, күңелләрендә йөрткән рәхмәт хисләрен укытучыларына җиткерде. Еллар үтү белән ачыкланганча, укытучы апалары аларга үз фәнен генә өйрәтеп калмаган, тормыш дигән авыр юлга да әзерләгән икән...

● Бездә кунак бар

# Җир хокукын өйрәндек

**Башы 1нче биттә.**

Геннадий Волков тикшергән проблемаларның берсе: РФ Җир кодексында каралган җирләр бүленешенең логик яктан җитешсез булуы. Профессор сүзләренә караганда, җирләрне максатчан файдалану төренә карап бүлү күп кенә хөкем эшләрендә аңлашылмаучанлыклар тудыра. Аның фикеренчә, бу мәсьәләне хәл итәр өчен әлеге бүленеш системасыннан баш тартып, җирләрне зоналарга бүлеп карау дөресрәк булыр.

Белгечне борчыган тагын бер проблема: Россиядә җир участокларын туплаган тулы бер мәгълүмати ресурс булмау. Геннадий Волков әйтүенчә, электрон документлар системасына күчү нәтиҗәсендә җир милкенә ия булучылар турындагы күп кенә мәгълүмат юкка чыккан. Электрон документлар тенденциясе бүген зур үсеш ала. Җирләрнең чын хуҗасын еш кына ачыкларга да мөмкин түгел. Моннан тыш, интернет кулланучыларының хокуклары арту, электрон документларга керү мөмкинлегенә ия булу нәтиҗәсендә, сайтларны ватып, җир участокларын урлау очраклары саны шактый арткан.

Геннадий Волков фикеренчә, совет заманында эшләп килгән җир хокукы системасы, бүгенгесе белән чагыштырганда, күпкә үтемлерәк һәм камилрәк булган. Картотекалар белән эшләгәндә, мәгълүмат тулы һәм төгәл сакланган, җир урлау очраклары бөтенләй булмаган диярлек.

Ачык лекцияләр барлык тыңлаучыларга кызыклы аналитик мәгълүмат, алга таба бу өлкә турында фикерләргә, студентларга үз нәтиҗәләрен ясарга этәргеч бирде.


Алия Галимуллина фотосы

● Илһам канатында

# Иҗат бердәмлеге

**Элвина НӘҖИПОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

«Илһам» әдәби-иҗат берләшмәсенең чираттагы утырышына «Дарелфөнүн» газетасы хезмәткәрләре килде. Бу көнне без газета эшчәнлегенә бәйле сорауларыбызга җавап алдык, хезмәткәрләре белән рәхәтләнеп аралаштык.

Иҗат кешесенә нәрсә кирәк? Илһам! Аллага шөкер, безнең «Илһам»ыбыз бар. Тагын иҗат иткән җимешләребезне укучыларга тәкъдим итү өчен мәйдан кирәк! Шөкер, монсы да бар. «Дарелфөнүн»ебез мондый мөмкинлекне һәрдаим тудырып тора. Очрашуга килгән мөхәррир, яраткан шагыйребез Рифат Сәлах та: «Безгә языгыз. Проблемаларыгыз булса, мөрәҗәгать итегез, бергәләп чишәрбез. Без сезнең мәкаләләргә сусап торабыз», – диде.

Очрашуга хәбәрчеләр: Динара Әхмәтова, Алинә Садыйкова, Динара Зиннәтова да килгән иде. Алар үзләренең студент еллары, ничек редакциягә эшкә урнашулары турында сөйләде. Уен-көлке белән үрелеп барган җылы очрашуда «Дарелфөнүн»нең ни өчен шундый бай эчтәлекле, кызыклы, мәгълүматлы итеп чыкканын аңладык. Хезмәткәрләр бик яшь булуларына карамастан, үз эшләренең осталары. Һәр нәрсәне җиренә җиткереп башкаралар, тагын да камилләшү өстендә юлын эзлиләр. Казан федераль университетында татар матбугаты булу, аның студентларны мәгълүматлы итүе, һәр атна саен безне кызыклы башваткычлар, матур шигырьләр, кызыклы хикәяләр белән «сыйлавы» – зур бәхет. Без аның чыкканын зарыгып көтеп алабыз. Шуңа күрә «Илһам» түгәрәгенә дә рәхмәтебез чиксез зур.

Утырышка Н.И.Лобачевский ис. математика һәм механика институтыннан, Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институтыннан иҗатташ дусларыбыз килү безне тагын да берләштерә. Фикер алышып, теләк-тәкъдимнәрне уртаклашабыз. Бу юлы да, һәркайсыбыз диярлек, яңа гына табадан төшкән әсәрләребез белән таныштырдык. «Дарелфөнүн» газетасы хезмәткәрләре белән уен да оештырдык. Рифат Сәлах тәкъдим иткән шигъри юлларны дәвам итеп, кызыклы гына шигырь иҗат иттек. Ни турыда язганыбызны күрмәсәк тә, бер төрле уйлавыбызны сез дә сизеп алырсыз.

*Әкиятләрдә йөри безнең Илһам*
*Юлы аның шуннан башлана.*
*Әкиятләр безгә яхшы мәктәп,*
*Ходай рәхмәтеңнән ташлама!*
*Мин бер ни аңламый утырам,*
*Ә син зинһар мине ташлама!*
*Дәрес бара, йоклама!*
*Сөер итеп як-ягына карана.*
*Бик күп кеше инде онытылган*
*Иҗат итүне син ташлама.*
*Еракларга очты безнең хыял,*
*Йә, Ходаем, безне ташлама!*
*Өйгә кайтыр вакыт җитә,*
*дуслар,*
*Карап тора миңа яшь ара.*



Автор фотосы

● 25 ноябрь - Әниләр көне

# Кая ул җәннәт ачкычы?

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты студенты

Әни... Нинди илаһи сүз! Аны һәркем үзенең иң кадерле, иң якын кешесенә әйтә. Шушы гади генә сүз үз эченә күпме шатлык һәм кайгы хисен берләштерә. «Әни» сүзе һәркемнең йөрәгендә, күңелендә туа, ә йөрәктән чыккан сүз йөрәккә барып керә. «Әни» дип эндәшә алган кеше нинди бәхетле!

Кемнәрдер бу бәхеттән мәхрүм бит. Гаепнең кемдә икәне дә билгесез... Уйлап карасак, Татарстанда гына да күпме картлар йорты! Һәммәсендә диярлек ялгыз әбиләр, әниләр... Үзләре теләп тә китмәгәндер? Тормыш шулкадәр явызмы, әллә аны без шундыйга үзгәртәбезме? Нигә яшәү бүләк иткән кешеләрдән шулай көләбез, аларны рәнҗетәбез? Еласак, юаткан, моңлы бишек җырлары җырлап йоклаткан, татлы йокыбыздан иркәләп уяткан; авырсак, терелткән; уңышларыбызга сөенгән, кайгыларыбызга көенгән; үзенең күңел, йөрәк җылысын, мәхәббәтен кызганмаган, гомер буе безгә иң зур терәк, яшәү өчен көч биргән кайбер әниләребезне бүгенге көндә без картлар йортында күрергә мәҗбүр...

Бер әни ике малай үстерә. Улларын шундый ярата, шуңа күрә аларның җәфаланып эшләүләрен теләми. Бөтен авыр хезмәтне җиң сызганып үзе башкара. Бервакыт әниләре авырып китә. Урын өстендә яткан ананы белүче дә, ишетүче дә булмый. Малайлар да игътибар итми, шау-гөр килеп уйнауларын дәвам итә. Берничә көннән соң әни кеше кош булып күк биеклегенә очып китә. Уллары: «Әни китмә, китмә», – дип кычкырып кала. Алар шулвакыт иң кадерле, иң газиз кешеләрен югалтканны аңлый. Ләкин соң була...

Җир йөзендә әниләр күп... Алар арасында балалары, оныклары, туганнары янында бик бәхетлеләре дә, еллар буе балаларыннан бер җылы, назлы сүз ишетмәүче бәхетсезләре дә шактый. Яраткан язучым Ә.Еникинең шундый сүзләре бар: «Ана бик яшьли үлеп китсә дә – ана, ә баласы сакалы агарып бетсә дә – бала! Мәңге бурычлы бала!» Тормыш йөген ир-ат белән бергә җигелеп тартучылар да, гаилә учагын сүндерми саклаучылар да – әниләр. Аналарның хакын хаклап, кадерен белеп, иманлы булсак кына аналарның аяк астындагы җәннәт ачкычы табыладыр.

«И газиз балалар! Ата-аналарыгыз сезгә иң авыр хезмәтләрне кылдылар, һәрвакыт сезнең өчен тырыштылар. Инде сез дә аларның бу яхшылыкларын камил кылып кайтарыгыз, көчегездән килгәнчә аларга чын күңелдән хезмәт итегез, хөрмәт күрсәтегез!» Рәсүлебез хәдисендә язылган бу изге сүзләрнең мәгънәсенә һәркем төшенсен иде дә бит...

***P.S.** 25 ноябрь – Әниләр көне. Җир йөзендәге барлык аналарны, шул исәптән университетыбызда эшләүче әниләрне дә әлеге бәйрәм белән тәбрик итәбез. Тыныч, имин тормыш, бәхетле киләчәк теләп калабыз!*

**• Әдәби Ат**

Бу көннәрдә «Иделем Ак-чарлагы – 2012» бәйгесенә йомгак ясалды. ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының «Идел» яшьләр үзәге оештырган конкурсның йомгаклау этабы биш көн барды. Шагыйрьләр Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Илсөяр Иксанова, язучы Марат Закир, тәнкыйтьче, галим, КФУ доценты Әлфәт Закирҗанов яшь иҗатчыларның әсәрләренә бәя бирде. Җиңүчеләр арасында университетыбыз студентлары да бихисап. Драма номинациясендә икенче урынны Чулпан Гобәйдуллина (Филология һәм сәнгать институты), проза буенча икенче урынны Алсу Нургатина (Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты) яулады. Кызыксындыру бүләкләренә төрле номинацияләрдә Энҗе Ибраһимова (Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара бәйләнешләр институты), Сиринә Мөхәммәтҗанова (МКСФИ), Ләйсән Исмәгыйлева, Гүзәл Фарсыева (ФСИ) лаек булды. Ә проза номинациясендә җиңүче КФУның Филология һәм сәнгать институты студенты Алмаз МАНСУРОВның хикәясен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.

# Куян сүзе - сәламәтлекнең үзе!

**Алмаз МАНСУРОВ,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Сәлам! Әйе, сиңа эндәшәм, дустым. Мин – куян! Синең кебек кешеләрнең хыял илендә яшәргә сәләтле җан иясе. Мине эзләп тә таба алмыйсың, карап та күрмисеңме? Борчылма, минем белән аралашыр өчен, сиңа бераз тырышлык кирәк булачак. Әйдә башлыйк. Хәзер син күңел күзеңне ач та, мине үз хыял дөньяңа керт.

Күз алдыңа китер. Мин уч төбе хәтле генә мамык йомгак, ап-ак минем йомшак күлмәк. Шул йомгактан чыккан аяк-куллар, артта нәни генә койрык булыр. Күзләрем минем кызыл, колакларым бик озын. Як-якка туктаусыз хәрәкәт итә борыным, тәмле кишер кимерәм, ачса әгәр карыным.

Кешеләрнең сәламәтлекләре какшаган, нык авырыйлар диеп таралды урманыбызда хәбәр, ярдәм итә алырмын төсле тоелды бер вакыйга сөйләсәм әгәр.

Күптән түгел урманыбызга килде зур афәт. Көтмәгәндә бүреләр ашый алмый, бурсыклар йоклый алмый башлады. Куяннарның тешләре коелды, аюларның аягы оеды. Тиеннәрнең сирәкләнде йоннары, боланнарның кысылды тыннары. Кошлар каурыйсыз калды, кабыксыз күкәй салды. Бар җәнлекләрнең бетте хәлләре, бик авыр узды һәрбер көннәре.

Бу хәлне күреп урманыбыз санитарлары тукраннар: «Булмый болай, туганнар», – диделәр дә җыелыш җыйдылар.

Йөри алган барлык урман халкы киң аланга агылды. Сөйләүчегә басарга агач төбе табылды. Озак көттермичә сүзне баш тукран алды. «Без киңәштек, уйлаштык һәм бер карарга килдек. Безгә ярдәмгә физик күнегүләр килер».

Читтә кояшта яткан аю кушылды шунда сүзгә: «Бер соравым бар, дусларым, сезгә. Физик күнегүләрне ашап буламы? Аларны ашасаң, корсак туламы?»

«Куркынычмы алар?» – диде болан да: «Куркыныч булса, сөзәрмен алар янымда булганда».

«Тынычланыгыз!» – диде шунда тукран. «Хәрәкәтләнергә туры килер, туган. Кирәкми аны хәтта сөзәргә. Сәламәт булыр өчен кирәк йөзәргә. Әйбер ташырга, сикереп уйнарга. Күбрәк эшләргә, шөгыль эзләргә».

Урманда шуннан эш китте хутка. Боланнар җыелып китте походка. Тиеннәр агачтан-агачка сикерде, куяннар узышып-узышып йөгерде. Бөҗәкләр тыз-быз чабышты, бүреләр үзара ярышты. Аю бүрәнә чөеп уйнады, күпме уйнаса да уйнап туймады.

Ә керпе дус үзенә күнегү эзләп карады... Күпме эзләсә дә эзләп тапмады. Шулай да тәпиләрен бөкте турайтты, үзенчә шулай мускул зурайтты. Файдасы, әлбәттә, тими калмады, күтәрде керпе бер зур алманы.

Җәнлекләрнең, кошкортларның хәле яхшырды. Шулай диеп бераздан саесскан тукранга рапорт тапшырды. Пошиның мөгезе ныгыды күптән, аюның да чире инде үткән. Куяннар ай-яй бик тиз йөгерә. Тиеннәр агачтан-агачка сикерә.



Тукран игътибар белән тыңлады. Тыңлады да бик нык уйланды. Аннан урманга аваз салды: «Урман халкы тыңлагыз, тыңлагыз. Авыз ачып тормагыз. Бәйрәм булсын, зур бәйрәм. Сәламәтлек бәйрәмендә уйныйк әйләнбәйлән».

Шуннан дөнья ямьләнә башлады. Кинәттән җыр сузды урман кошлары. Күбәләкләр чуар күлмәген киде, ерактан кунакка шаян җил килде. Ул каеннарның чәчен таратты. Шуклыгы белән урманны шаулатты.

Керпе бәйрәмгә ташыды алмалар. Алар кызыллар, алар баллылар. Куянның кишере торды кетердәп. Йомырка китерде бәйрәмгә үрдәк. Аю алып килде бал бер мичкә, аны бетерделәр ашап шул кичтә.

Ә физик күнегүләр безнең яшәү рәвешенә әйләнде, шуңа күрә дә тормышыбыз ямьләнде. Сәламәт тәндә сәламәт акыл бар. Җиңә алмас безне моң-зар. Хәзер дә сикереп, йөгереп, уйнап сәламәтлекне саклап яшибез. Бездән үрнәк алыгыз, дусларым!




## Телләр белгән - илләр гизгән

ПОЛИГЛОТ языковой конкурс

**29-30 ноябрь көннәрендә КФУ тел белгечлеге булмаган студентлар арасында «Полиглот» чит телләр конкурсы уздыра.** РФның барлык вузларыннан да тел белгечлеге алмаган студентлар катнаша ала.

Конкурс кысаларында ике номинация: «Полиглот» (ике чит тел) һәм «Тәрҗемәче» (бер чит тел) игълан ителә. Конкурс 4 тел юнәлеше буенча узачак: инглиз, немец, француз һәм испан телләре. «Полиглот» номинациясендә катнашу өчен, ким дигәндә, конкурс программасында игълан ителгән ике телне белергә кирәк.

Конкурс ике этапта үтәчәк. Беренчесе аудирование, лексик-грамматик тестлар, чит телдә язылган текстны аңлау кебек биремнәрне үз эченә ала. «Полиглот» номинациясенең икенче этабында ике чит телдә сөйләргә, ә «Тәрҗемәче» номинациясендә спорт тематикасына язылган текстны телдән русчадан башка телгә тәрҗемә итәргә кирәк.

Программага тәҗрибә уртаклашу рәвешендә түгәрәк өстәл, алдынгы белгечләрдән мастер-класслар, Казан шәһәренең истәлекле урыннарынна экскурсия кертелгән.

Конкурста катнашырга теләүчеләр тулырак мәгълүматны _KPFU.ru/main_page?p_lid=18848_ адресы буенча белергә мөмкин. Заявкагызны бүген үк җибәрегез.



**22 ноябрь көнне** Филология һәм сәнгать институтының **«Мизгел» халык театры** Туфан Миңнуллин истәлегенә багышлап, аның **«Саташу» спектаклен тәкъдим итә**. Татарстан урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан уку бинасының актлар залына рәхим итегез. Башлана: **18:00 сәгать**. Керү ирекле.

**• Шигъри башваткыч**

## *Сак-сак тотсак!*

*(Ребус-такмак)*

**Ринат НУРУЛЛИН**

*Кайнар чәй телне пешермәс,*
*Сак-сак йотсак!*
*Балык кармактан ычкынмас,*
*Сак-сак тартсак!*

*Сабын куыгы шартламас,*
*Сак-сак тотсак!*
*Керпе инәсен кадамас,*
*Сак-сак тотсак!*

*Һәр цифрны хәреф белән*
*Алмаштырсак,*
*Мондый ребус килеп чыгар:*
*САК x САК = ТОТСАК.*

*Бернигә дә ирешмәбез,*
*Эшсез торсак!*
*Кем ребусны чишә алмый,*
*Шул – капкорсак!*

**!** Алдагы санда чыккан башваткычның җавабы:
37037 X 3 = 111111.

Җиңүчебез Алинә ГАНИЕВАны редакциябездә «Альпинист үрмәкүчләр» китабы көтә! Дуслар, хәзер «Шигъри башваткыч» лигасында һәр дөрес җавап исәпләп барыла. Дөрес җавапны беренче җибәрүчегә – 10, икенче урынга – 8, өченчегә – 7, калган урыннарга 5 һәм аннан кимрәк балл бирелә. 10 шигъри башваткыч чыккач, лигага йомгак ясаячакбыз. Беренче өч урынны истәлекле бүләкләр көтә. Лигада 22 балл белән Илмир Вәлиев әлегә беренче урында бара. Икенче Алинә Ганиева 18 балл, Руфинә Габдрахманова 10 балл туплап әлегә өченче.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.